| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 09.12.2016 г. Казань № 10-38/кс

2017-2019 елларга “ЗВКС” акционерлык җәмгыяте өчен эчергә яраклы суга һәм су бүлүгә тарифлар билгеләү турында

“Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында” 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ санлы Федераль законга, “Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында” 2013 елның 13 маендагы 406 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, “Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә җайга салынучы тарифларны исәпләп чыгару буенча Методик күрсәтмәләрне раслау турында” тарифлар буенча Федераль хезмәтнең 2013 елның 27 декабрендәге № 1746-э санлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне башкаручы “ЗВКС” акционерлык җәмгыяте өчен эчергә яраклы суга һәм су бүлүгә тарифларны билгеле бер календарь чорларына бүлеп, әлеге карарның 1 кушымтасы нигезендә билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2017 елның 1 гыйнварыннан 2019 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. 2017-2019 елларга салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне башкаручы “Иннополис” махсус икътисадый зона” акционерлык җәмгыяте өчен эчергә яраклы суга һәм су бүлүгә тарифларны озак вакытка исәпләнгән җайга салу параметрларын әлеге карарның 2 кушымтасына нигезләнеп билгеләргә.

4. “ЗВКС” акционерлык җәмгыятенә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 санлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча халыкка җиткерелергә тиешле мәгълүматны ачарга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының
тарифлар буенча Дәүләт
комитетының 09.12.2016 № 10-38/кс
карарына 1 кушымта

## Тарифы 2017-2019 елларга салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне башкаручы ЗВКС” акционерлык җәмгыяте өчен календарь чорларын бүленгән эчергә яраклы суга һәм су бүлүгә тарифлар

| № п/п | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су бүлүне бакшкаручы оешманың атамасы, | Эчергә яраклы суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.метр | | | | | | Су бүлүгә тариф (бер ставкалы), сум/куб.метр | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2017 ел | | 2018 ел | | 2019 ел | | 2017 ел | | 2018 ел | | 2019 ел | |
| | | 01.01.2017 алып 30.06.2017 кадәр | 01.07.2017 алып 31.12.2017 кадәр | 01.01.2018 алып 30.06.2018 кадәр | 01.07.2018 алып 31.12.2018 кадәр | 01.01.2019 алып 30.06.2019 кадәр | 01.07.2019 алып 31.12.2019 кадәр | 01.01.2017 алып 30.06.2017 кадәр | 01.07.2017 алып 31.12.2017 кадәр | 01.01.2018 алып 30.06.2018 кадәр | 01.07.2018 алып 31.12.2018 кадәр | 01.01.2019 алып 30.06.2019 кадәр | 01.07.2019 алып 31.12.2019 кадәр |
| | Яшел Үзән муниципаль районы | | | | | | | | | | | | |
| 1 | “ЗВКС” акционерлык җәмгыяте | | | | | | | | | | | | |
| 1.1 | Халык (тарифлар НДС белән күрсәтелгән)* | 18,22 | 18,75 | 18,75 | 19,64 | 19,64 | 20,23 | 16,86 | 17,63 | 17,63 | 18,05 | 18,05 | 18,87 |
| 1.2 | Башка кулланучылар (тарифлар НДСтан тыш күрсәтелгән) | 15,44 | 15,89 | 15,89 | 16,64 | 16,64 | 17,14 | 14,29 | 14,94 | 14,94 | 15,30 | 15,30 | 15,99 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 маддәсе 6 пунктын гамәлгә ашыру максатыннан чыгып бүлеп бирелә

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештыру һәм җайга салу бүлеге

Татарстан Республикасының
тарифлар буенча Дәүләт
комитетының 09.12.2016 № 10-38/кс
карарына 2 кушымта

2017-2019 елларга салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне башкаручы “ЗВКС” акционерлык җәмгыяте өчен календарь чорларын бүленгән эчергә яраклы суга һәм су бүлүгә тарифлар

| № п/п | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су бүлүне бакшкаручы оешманың атамасы, тариф төре | Ел | Операцион чыгымнарның нигез дәрәҗәсе | Операцион чыгымнарның нәтиҗәлелек индексы | Табышларның норматив дәрәҗәсе | Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | су югалту дәрәҗәсе | электр энергииянең чагыштырма чыгымы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·сәг./куб.м |
| 1 | “ЗВКС” акционерлык җәмгыяте | | | | | | |
| 1.1 | Эчергә яраклы су | 2017 | 73 174,64 | 1 | - | 14,14 | 0,89 |
| | | 2018 | 75 290,50 | 1 | - | 14,14 | 0,89 |
| | | 2019 | 77 467,81 | 1 | - | 14,14 | 0,89 |
| 1.2 | Су бүлү | 2017 | 83 028,75 | 1 | - | - | 0,56 |
| | | 2018 | 85 491,42 | 1 | - | - | 0,56 |
| | | 2019 | 88 025,89 | 1 | - | - | 0,56 |

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештыру һәм җайга салу бүлеге